ГЛАВА НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.11.2021 с. Старое Русское Маматкозино 01

Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең Татар Мәмәтхуҗасы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021нче елның 7 нче ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең Татар Мәмәтхуҗасы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2022нче елда Югары Ослан муниципаль районының Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлегенең Татар Мәмәтхуҗасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- Татар Мәмәтхуҗасы авылында буаны төзекләндерү.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Татар Мәмәтхуҗасы авылы, Кояшлы урамы, 9 нчы йорт адресы буенча 11.00 сәгатьтә Гимадиев Ф.А. йорты янында үткәрергә.

4. Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгы В.В.Никитушкин